Татарстан яшьләре

N 43

(8765)

ШИМБӘ

10 апрель, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *



Йөзебез нинди?

Башта бер анекдот.

Илебез башкаласы Казан. Тимер юл вокзалы. Поездддан бер кулына чемодан, икенче кулына карбыз тоткан кунак килеп төшә. Ул чемоданын җиргә куя һәм кулын Сөембикә манарасы ягына сузып сәлам бирә:

- Исәнме, кояшлы Казан!

Чемоданын алыйм дип иелсә - аннан җилләр искән.

Кунак вәсвәсәләнеп кычкыра башлый:

- Милиционер! Милиционер!!!

Каршына ашыкмый гына милиционер килеп баса!

- Нәрсә булды, гражданин?

- Менә, чемоданны сукканнар!

- Бик әйбәт, очына чыгарбыз. Тик нигә менә бу кулыгыз кәкерәйгән?

- Каһәр генә суксын! - дип кычкырып җибәрә кунак. - Карбызны да шудыртканнар.

Бу анекдот әлеге фотоны күргәч искә төште. Казаныбызның иске вокзалы бүген менә шушындыйрак хәлдә. Ә яңасы, инде ничәмә-ничә еллардан бирле төзелә башлап, ташланган хәлдә ята. Килгән-киткән кеше шәһәрнең йөзен вокзалына карап билгели. Көн саен дөньяның төрле илләреннән кунаклар кабул итүче Казанга мондый вокзал белән яшәп яту бер дә килешми инде, җәмагать. Мәркәзебез вә мәмләкәтебез, ягъни башкалабыз һәм илебез өчен уңайсыз.

Евгений КАНАЕВ фотосы.

Казанда - 294, Ижауда - 792, ә Уфада...

Киләсе яртыеллыкка "Татарстан яшьләре"нә язылу бәясе нибары 294 сум дип язган идегез. Язылырга дип почтага керсәм, ни күрим, язылу бәясе 792 сум дип акка кара белән язылган. Яратып укыган газетам белән бәхилләшергә туры килер микәнни? Зинһар, аңлатыгыз, нәрсә бу? Нинди аерма?

Гөлфинә ФӘССАХОВА.
Ижау каласы.

- Әйе, бар шундый аерма, - дип аңлатты безгә республикабызның Дәүләт һәм информатика предприятиесенең почта хезмәте һәм матбугат тарату бүлеге начальнигы урынбасары Л.И.Овчинников. - 294 сум - бу "Татарстан яшьләре"нә язылуның тулы бәясе түгел, ә бәлки Татарстан Информация һәм мәгълүмат министрлыгы тарафыннан куелган һәм республика халкы өчен дотацияләнгән (җиңеләйтелгән) бәя. Әгәр республика хөкүмәте матбугат тарату чыгымнарын дотацияләмәгән булса, бездә дә "Т.Я."нең бәясе әлеге дә баягы Ижаудагыдан ким булмас иде.

Менә шулай, чит өлкәләрдәге хөрмәтле укучыларыбыз. Сезгә ходай сабырлык бирсен дияргә кала. Нишлисең, бәяләр көнләп түгел, сәгатьләп үскән бу заманда безне гаҗәпләндерерлек хәлләргә, телисеңме-теләмисеңме, әзер булып торырга туры килә. Чит төбәкләрдән килгән хатлардан күренгәнчә, "Татарстан яшьләре"нә язылу бәясе төрле җирдә төрлечә булырга охшый. Әйтик, Башкортостанда ул 516 сум икән. Күрәсең, бу аерма почта чыгымнары белән бәйледер. "Татарстан яшьләре"нә язылу кайда, ничек бара, нинди бәядән - шул хакта сездән хатлар көтәбез. Тотрыксызлык, замана кыенлыклары "Татарстан яшьләре" белән дуслыкны дәвам иттерүдә сезгә киртә булмасын дигән теләктә калабыз.

"Татарстан яшьләре" редакциясе.

Көнбатыш безгә ышана

Татарстан һәм Саксониянең белгечләр төркеме ике ил арасында хөкүмәтара килешүне әзерләп бетерделәр. Шул уңайдан Татарстанның Тышкы икътисадый элемтәләр министрлыгында (ТИЭМ) азат Саксония җире (ГФР) ландтагының (парламентының) бюджет һәм финанслар буенча комиссиясе рәисе Ф.Тидт әфәнде матбугат конференциясе үткәрде.

Аның сүзләреннән аңлашылганча, алманнар илебезнең сәнагать потенциалын югары бәялиләр һәм безгә хәрби предприятиеләрне конверсияләү эшендә булышырга телиләр. Әлбәттә, Саксония үзенә дә табыш алачак. "Свияга", "АлАЗ", "КамАЗ"" һәм башка заводларда уртак проектлар тормышка ашырылачак. Димәк, Татарстанда эш урыннары кимемәячәк дип ышандырырга була.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, югарыда әйтеп үтелгән хөкүмәтара килешү Мәскәү һәм Бонны катнаштырмыйча төзелде.

Шулай итеп, Татарстан һәм Саксония сөйләшүләрдән конкрет эшкә, хезмәттәшлеккә күчтеләр.

Ә 4-8 майларда Казанга Саксония хөкүмәтенең финанслар министры һәм җирле банк директоры эш визиты белән киләчәкләр.

Рөстәм КИРАМОВ.

Татарстан яңа базарлар эзли

Бүген Мисыр башкаласы Каһирә шәһәрендә ел саен үткәрелә торган "Каһирә-93" исемле сәүдә-сәнәгать ярминкәсе ачылды.

Ярминкәдә Татарстан экспозициясе дә бар. Илебез тарихында моңарчы күрелмәгән факт бу. Безнең стенд өстендә дәүләт байрагыбыз һәм гербыбыз урнаштырылды. "Түбән Кама-шин", "Сантехприбор", "Мединструмент" берләшмәләре, Гамәли оптика дәүләт институты үз товарларын күрсәтәләр.

Ярминкәне ачу тантанасында Татарстанның тышкы икътисадый элемтәләр министры Шәүкәт Арсланов катнашты.

Равил САБЫР.

Сер итеп кенә

Студентка ничек акча эшләргә?

Ачлыкка интегүче бер студент әти-әнисенә телеграмма сукканда акча азрак тотылсын өчен әйтергә теләгән фикерен "СТУДЕНТ" дигән сүзгә ("Срочно требуются уйма денег есть нечего точка") сыйдырып бетергән имеш. Чаллы дәүләт педагогия институтында укучы студентлар да хәзер шундый кыскартылма сүзләргә өмет баглап яши башладылар. Аларны бигрәк тә "СТОП" ("Студенческое творческое объединение по пошиву") кызыксындыра.

Студентларның тегү буенча оештырылган иҗади берләшмәсе әле санаулы гына ай элек оештырылса да, аны инде Чаллыда белмәгән кеше юктыр.

- Безне эш белән бер кече предприятие тәэмин итә. Шуңа безгә тукыма табу, тегелгән әйберләрне сату проблема түгел, - ди студентлар профкомының рәисе Игорь Әһлиутдинов.

Минем әңгәмәдәшем институтның ректоратына, укытучыларына да зур рәхмәтле. Әгәр алар бу башлангычны хупламасалар, үзләре дә кызыксынучанлык күрсәтмәсәләр, гап-гади тегү машиналарын гына да каян табар идең?! Дөрес, биредә эшләүче студентларны хәзергә бай яшиләр дип булмый. Тик шулай да студент кесәсендә дә хәзер һәрвакыт акча йөри. Мәсәлән, дүрт студент көненә ике чалбар гына тексәләр дә, һәркайсы бишәр мең сум акчалы була дигән сүз. Әле ул сан күбрәк тә булыр иде. Әмма табышның яртысы студентларга матди ярдәм күрсәтүгә тотыла. Чаллы студентлары бүгенге хәерчелектән әнә шулай чыгарга тырышалар. Эшләр уңайга китсә, студентлар тегүчеләрне дә уздырмагайлары.

Б.ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВ.
Чаллы.



Президент М.Шәймиев Кремльдә Кырым Республикасы парламенты делегациясен кабул итте. Сөйләшүләр барышында ике республика арасында эшлекле элемтәләр булдыру мөмкинлекләре барланды, конкрет тәкъдимнәр каралды. Рәсми делегация Татарстанның машиналарына, нефть продуктларына, полиэтиленына, газына, төрле торбаларына балык ризыклары, яшелчә һәм җиләк-җимеш, балалар ризыгы, тәмәке һәм башка товарлар бирергә мөмкинлек булуы турында белдерде. Сөйләшүләр дәвам итә.

Вице-президент В.Лихачев АКШ эшмәкәрләрен кабул итте. Әңгәмә Татарстан һәм АКШ арасында финанс һәм банк эше өлкәсендә ике як өчен дә файдалы булган хезмәттәшлек урнаштыру турында барды.

Төркиядә эш визиты белән булып кайткан Премьер-министр М.Сабиров җитәкчеләр белән киңәшмә үткәрде. Ул анда визит барышында булып үткән сөйләшүләрнең нәтиҗәләре, конкрет программаларны гамәлгә ашыру буенча төрек эшмәкәрләре һәм фирмаларның теләкләрен җиткерде һәм ике ил арасындагы мондый хезмәттәшлекне алга таба тагын да киңәйтергә кирәклеген билгеләде.

Татарстан Эчке эшләр министрлыгы ведомство һәм ведомстводан тыш булган сакчыларны ау мылтыклары һәм газ белән ата торган корал белән коралландыру турында карар кабул итте. Бу чара халык хуҗалыгы объектларын талау очракларының бермә-бер артуын күздә тотып эшләнә.

Казанда опера җырчыларының Ф.И.Шаляпин исемендәге III Халыкара конкурсы бара. Җиңүчеләрне моңарчы күрелмәгән бүләкләр көтә. Гран-при иясенә (ул бас тавышлы булырга тиеш) - 2000 доллар, беренче урынга - 800 000 сум, икенчегә - 500 000 сум, ә өченче урынны алучыга 300 000 сум акча биреләчәк. Моннан тыш жюри әгъзасы булган бразилияле Хелена Оливейра үзенә иң ошаган җырчыга 1000 доллар бүләк итәчәк. Бүләк дәгъва итүчеләр арасында Казаннан бер генә җырчы - А.Беркович.



Гөлгенә ФӘХЕРТДИНОВА

Бозлар ага...

Кышлар узган,
тагын язлар җиткән,
Елгаларда, әнә, бозлар ага.
Бозлар түгел,
күңелдәге сагыш
Дәрья булып ярларына кага.

Кышларымда көткән идем сине,
Күренмәдең никтер...
йөрәк яна...
Синсез үткән минутларны санап,
Елгаларда, әнә, бозлар ага.

Теге ярда калдың,
мин - бу ярда,
Җимерелде күпер -
бозлар ага.

Сагынуларым, сагышларым бүген
Күз яшьләрем булып
суга тама...
Бозлар ага һаман, бозлар ага...

Фаил ЗӘЙНУЛЛИН фотосы.

Исхакыйсыз, Ибраһимовсыз, яки фәкыйрьлек белән үткән тереклек...

Безнең буынга урта белемне иң каһәрле елларда алырга туры килде. Болар - дәһшәтле геноцид - 1937 ел; аннан - әлифба алыштыру, Балтик буен басып алу; аннан - Ватан сугышы. Бу еллар ачлык, фәкыйрьлек еллары гына түгел, рухи имгәнү, чирләү еллары да иде.

Күз алдына китерегез: ач, корчаңгылы татар баласы салкын класста бияләй киеп утыра. Тәрәзәдән кар керә. Әдәбият дәресе: элек безнең халкыбыз фәкыйрь булган, ач булган, хәзер без рәхәттә яшибез. Бөтен укыганыбыз элекке фәкыйрьлек белән үткән тереклек турында. Котчыккыч: бүгенге тормышың да фәкыйрьлектә, укыган әдәби әсәрең дә нәкъ шул турыда. Бала күңелендә нинди матур уйлар тусын! Синдә нинди гүзәллек тойгылары тәрбияләнсен? Бездән кем чыксын?

Баксаң-күрсәң, татар тормышы алай фәкыйрь булмаган икән. Әнә, Фатих Әмирхан яшьләре, әнә Галимҗан Ибраһимов персонажлары ("Табигать балалары", "Яшь йөрәкләр", "Яз башы"), әнә, Гаяз Исхакый геройлары ("Ул әле өйләнмәгән иде"), Садри Җәләлнең "Дим буенда" әсәрләрендәге яшьләр... Юк, татар мескен булмаган. Моны ихтимал безнең прозада беренче булып Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиевләр тасвирлагандыр. Әмма инде татар тормышы Гаяз Исхакый каләменә килеп кергәч, эш бөтенләй башкача. Исхакыйның егетләре, ирләре - изелгән мескен татар түгел, алар империя түрәсе алдында изелеп, калтырап тормыйлар, алар Мәскәү, Петербург белән эш итәләр, Финляндия урманы эчендә җәйгә дача алып ял итәләр, поездларда шәһәрдән-шәһәргә йөриләр, сәүдә итәләр, укырга китәләр.

Исхакый иҗаты татарларның Россия империясендәге бер милләттән дә ким булмавын, горур, эшлекле кешеләр икәнен тасвирлады. Ләкин бу - кадимче фразерларның "без - шанлы, данлы татарлар" дигән бушбугазлык тенденциясеннән бик ерак торган тасвир иде.

Исхакыйның бөтен иҗаты, тормыш юлы безне эшлекле булырга, елак, мескен булмаска, үз халкың өчен көрәшә белергә өйрәтә, шуңа өнди.

Исхакый әсәрләрен мәктәпләребезнең дүртенче классыннан алып өйрәнә башлыйк әле - татар баласының эчке дөньясы, дөньяга карашы гаҗәеп матурланып китәчәк.

Бик кызганыч, Исхакый мирасы шулкадәр әкрын кайта әле безгә...

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ.

Кичә татар халкы Кәмал театрында үзенең бөек әдибе һәм фикер иясе, күренекле җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 115 ел тулуын билгеләп үтте.

Саумысез, татар генераллары!

Татар халкыдай төрле төбәкләргә һәм илләргә сибелгән халык сирәктер. Тарихыбыз, ачы язмышыбыз, табу һәм югалтуларыбыз хакында фәндә инде байтак язылган. Ә менә татардан чыккан хәрбиләр турында юньле-башлы мәгълүматны без тиз генә таба алмабыздыр, мөгаен. Юк андый хезмәтләр һәм Совет хакимияте чорында алар була да алмас иде. Әйтик, патша армиясендә татардан чыккан генераллар булганмы, булса - ничәү?

Ярый, инде якындарак елларга әйләнеп кайтыйк. Бөек Ватан сугышы көннәрендә татар да уртак Ватанны, ягъни Советлар Союзын яклар өчен утлы җәһәннәм эченә җибәрелде. Хакыйкатьне таныйк: СССР дип аталган элекке державага без - хәрбиләр дә, хәрби булмаганнар да - тугрылык белән хезмәт итә килдек. Бүтәнчә мөмкин түгел иде. Бүген исә чынбарлык бөтенләй бүтәнчә: ясалма юл белән төзелгән СССР таркалды, тоталитар режим сүтелде, шуның җимерекләре астыннан күтәрелгән япь-яшь, әмма борынгы тарихлы дәүләтләр мөстәкыйльлек юлына аяк басты. Татарстан Республикасы да, табигый ки, мөстәкыйльлек юлын сайлады. Инде хәзер яңача шартларда "ничә татар генералы бар икән соң?" дигән сорауга ачыктан-ачык җавап бирү мөмкинлеге ачылды.

Аңлашылса кирәк, татар хәрбиләренең очрашуын абруйлы, йогынтылы кеше генә оештыра ала иде. Безнең исә андый кешебез бар: ул - Союздагы төркиләрдән беренче буларак армия генералы дәрәҗәсен алган кеше, хәрби фәннәр докторы, академик Мәхмүт Әхмәтдин улы Гәрәев. Бүгенге көндә Русия Оборона министрлыгында хәрби киңәшче. Ягымлы карашлы, үз халкына мәхәббәте белән генерал киемнәреннән дә өстенрәк торган бу шәхес узган ел Казанда үткәрелгән Бөтендөнья татарлары конгрессында катнашты һәм саф татар телендә чыгыш ясады. Президентыбыз, дәүләт җитәкчеләре һәм аксакаллар белән Каен урманлыгында халкыбызның иң күренекле бәйрәмен - Сабан туен карады. Менә шундый кешенең татар хәрбиләре җыенын оештырудагы роле аңлашылса кирәк.

Мәскәүдә булачак очрашуга Казаннан дүртәү сәфәр чыктык: отставкадагы генерал-майор Гайнулла Шакиров, "Татар-информ" агентлыгының генераль директоры Гомәр Богдалов, журналист Нургали Булатов һәм мин. Иртән "Татарстан" поездыннан төшү белән безне яшь, чибәр, ачык йөзле полковник Васил Вәгыйзь улы Шәрипов каршы алды. Авиация кешесе икәнен әйтеп торган хәрби кием бик тә килешле үзенә. Очучы буларак, заманында ул байтак кына стратегик бомбардировщикларны һава киңлекләренә алып чыккан. Бүгенге көндә Генеральный штабта фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнә. Тагын да күңеллесе - якташыбыз икән: Балык Бистәсе районының Балтач авылында туып үскән. Өстәвенә, шагыйрь Равил Фәйзуллинның авылдашы, сабакташы... "Бер парта артында утырып укыган, бер чирәмдә уйнап үскән татар егетләренең кайсы шигърияткә, кайсы авиациягә китеп барган икән..." - дип уйлап алдым шул мәлдә. (Җаяләр эчендә булса да әйтеп китим, болай уйлавымның үзем генә белгән сәбәпләре бар: 1946 елгы бертуган абыем хәрби очучы иде, япь-яшь лейтенант килеш самолетта янып һәлак булды...)

Фатир ягыннан мәшәкатьләр булмады, без Генштаб кунакханәсенә урнаштык. Кичке яктарак Санкт-Петербургтан тагын дүрт кунак килеп төште: вице-адмирал Марс Җамал улы Искәндәров, генерал-лейтенант Мөнир Хәлил улы Колахмәтов, генерал-майор-инженер, РФ Академиясенең Информатика һәм автоматлаштыру институты директоры Рафаэль Мидхәт улы Йосыпов: генерал-майор Марсель Мотыйгулла улы Әһлиуллин. Билгеле инде, туганнарча күрештек, таныштык, шундук чәй хәстәренә керештек.

- Сезнең дәүләт җитәкчеләре, Татарстаннан икенче Кувейт ясыйбыз, дип әйтәләр икән. Дөресме бу? - дип сорады чал чәчле генералларның берсе.

- Ил башындагыларның рәсми төстә андый белдерү ясаганнары юк, - дидем мин, үзем белгәннәр кадәресенә таянып. - Әмма бу фикер митингларда, мәйданнарда һәм шулай ук көндәлек матбугатта еш әйтелә килә. Бу фикердә тирән дөреслек бар. Татарстан, чыннан да, зур нефть запасларына ия һәм ул аны дистә еллар буе, бушка диярлек һаман Россия кесәсенә агыза килде. Инде менә үзендәге табигый байлыкларга үзең хуҗа булыр көннәр җитте.

Җае чыгып, хәрби кунакларга "Казан утлары"ның 70 еллыгына багышланган юбилей саннарын тапшырам. Укучыларыбыз хәтерлидер: журнал тышлыгына Татарстан гербы сурәте урнаштырылган иде. Кызыл фонда канатлы ак барс, түгәрәк гербның чит-читләре исә милли нәкышлы яшел тасма белән әйләндереп алынган. Тышлыктагы герб сурәтен күргәч тә Марсель Әһлиуллин сокланудан балаларча куанып, ләкин олыларча җитдилек белән әйтеп куймасынмы:

- Менә моны безнең кительләрнең җиңсәсенә ябыштырсаң да ярый икән!

Әлеге сүзләр барыбызның да күңеленә хуш килде, билгеле. Елмаештык. Бу теләк, фикер һәммәбезгә сүзсез дә аңлашыла иде...

20 февраль көнне татар генераллары-адмиралллары, ниһаять, "Президент-отель" дигән гүзәл бинада очрашуга җыйналдылар. Исемлеккә 40лап хәрбинең исем-фамилияләре теркәлгән иде. Аларның барысы да диярлек СССРның элекке төбәкләреннән очрашуга килеп җиткәннәр. Парадный формада, ягъни бәйрәмчә киенгәнгә күрә, яшьме-картмы, аларның һәммәсе матур, күркәм, затлы күренә. Һәрхәлдә, генерал погоннары, чалбардагы буй-буй кызыл лампаслар һәм пөхтә кительләр күңелдә күтәренке бер халәт тудырды.

Мәхмүт ага Гәрәев, очрашуның хуҗасы буларак, иң элек кунакларны истәлек өчен фоторәсемгә төшәргә чакырды. Өсте гөмбәзләп эшләнгән зур, мәһабәт залның уртасына мәрмәр плитәләрдән зодиак картасының унике йолдызлыгы түшәп ясаганнар. Андый йолдызлык икән, түгәрәкнең бер өлешендә барс сурәте дә бар, билгеле. Фотографларның "черт-черт" итеп төшерүләренә карамастан, игътибарым зодиак боҗрасына, барыннан да бигрәк барс сурәтенә йотылды гына бит, шайтан алгыры! Әмма зодиактагы кара барс шулкадәр ябык һәм шөкәтсез иде, мин аны ничектер кызганып куйдым. Ни канаты юк, ни гайрәте сизелми тегенең...

Рашат НИЗАМИЕВ.

Хөрмәтле укучылар!

Татар генераллары турындагы кызыклы бу язманы сез тулысынча килеш "Казан утлары" журналының быелгы 5 нче санында укый алырсыз.

Редакциянең үтенече буенча, подписка башлану уңаеннан исегезгә төшерәбез: "Казан утлары"ның индексы - 73210, ярты елга язылу бәясе - 180 сум.

Идея бар!

Тирә-юнебездә андый кешеләр җитәрлек. Алар беркайчан да югалып калмыйлар. Төшенкелеккә бирелү алар өчен ят нәрсә. Теләсә нинди авыр хәлдән дә җиңел генә чыгу әмәлен табучы "башлы кешеләр" редакциягә хат юллаучы авторлар арасында да табылып тора. Бүгеннән башлап без андый укучыларыбызның хатларын "Идея бар" дигән махсус рубрикага туплап бирә башлыйбыз. Алга таба анда күпләрнең кызыклы идеяләре урын алыр дип ышанабыз.

Ә хәзер укучыларыбызны берничә идея белән таныштырабыз.

"Баллы" ял йорты кайда бар?

Безнең гаиләдә мин үземне белгәннән бирле умарта тоталар. Бабай һәм бабайның бабасы да умарта тоткан. Шулай булгач, умартачылык продукциясе турында нигезләнгән белешмәләрем бар, умартачылыкның файдасын җилкәмдә дә сынарга туры килде. Бозлы суга батып, 7-8 чакрым тайга буенча йөрдем, томау да төшмәде, кайнап торган су белән коендым, атна дигәндә тәнем яңа тире белән капланды. Хәер, нигә сөйләп торырга, борынгы бабайлар бит: "Бал 77 чирдән дәва", - дигәннәр.

Энекәш белән бергә, апитерапиягә нигезләнгән ял йорты төзегәндә шәп булыр иде, дигән карарга килдек. Ләкин энекәш тә, мин дә табиб түгел. Энекәш инженер-механик булса да, умартачы булып эшли, үзем нефть эзләүче геологларда топограф булып эшлим. Шуңа күрә бу тәкъдим белән кызыксынган чын табиб һәм шушы проектны тормышка ашыруда спонсор булырдай оешманың безгә хат язуына өметләнәм. Проектны тормышка ашыру өчен акча белән ярдәм итүче оешмага ким дигәндә 30-40% урынны даими гарантияләп булыр иде.

Безнең адреслар: 423738, Татарстан, Актаныш районы, Яңа Кормаш авылы, КӘШФРАЗЫЕВ Азамат.

Яки 626432, Төмән өлкәсе, Пыть-Ях шәһәре, Мамонтово поселогы, СП-16, КӘШФРАЗЫЕВ Илдус.

Бәхет Мәккәсе кирәк безгә...

Хәзер аерылышучы гаиләләр бик күп. Үз тиңнәрен таба алмаучы ялгызакларны гына ал - азмы алар бездә? Газета яисә төрле игъланнар аша пар канатлы булырга теләүчеләрне еш очратырга мөмкин. Әлеге проблеманы хәл итүдә миндә бер фикер бар. Әйтик, Казанда Ленин һәм Киров районнарына илтүче ике дамба буенда яки бүтән матур-матур урыннарда ялгызакларның җыелу урынын булдырырга иде. Бер-береңне үз күзләрең белән күреп очрашу-кавышу игъланнар аша танышуга караганда күпкә яхшырак түгелме соң? Сөембикә манарасы, цирк яннарын - Казан-су елгасы тирәләрен Бәхет Мәккәсенә әверелдерәсе иде. Казанның Дербышки поселогында да, Юдинода һәм башка урыннарда, шулай ук республиканың барлык районнарында да бәхет аллеялары - гаилә учагын кабындырып җибәрүгә булышлык итүче махсус урыннарны оештыруда мөмкинлек туар бәлки...

Ринат ГЫЙНИЯТУЛЛИН.
Казан шәһәре.

"Фронтовик"ны сәхнәдә күрәсе килә

Бу хатым Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрен яратучыларга адресланган. Укып сокланган, үзебезне, тирә-юнебездәге күп кенә кешеләрне гәүдәләндергән Мөхәммәт аганың әсәрләрен сәхнәләштерәсе һәм экранлаштырасы иде. Аларда безнең рух, эчке дөньябыз, татарлыгыбыз ташып тора. "Фронтовиклар"ны гына алыйк. Андагы Рушат, Гата, Нәркис, Ләйләгөл, Гөлчирәләрне сәхнәгә чыгару зур тәрбияви эш башкарыр иде. Мәдәният-сәнгать әһелләре, бу идеяга колак салсагыз иде.

Мәймүнә НУРМИЕВА.
Балтач районы, Борбаш мәктәбе.

ТВ АТНАЛЫК ПРОГРАММА

ДҮШӘМБЕ

12 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.30 Мультфильм.
18.40 Казан техник университетының беренче чыгарылышы.
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 Республика: сәяси көндәлек.
20.05 Әлли-бәлли-бәү
20.20 Ф.Вәлиәхмәтов җырлый.
20.50 "Синьорита". 1, 2 серияләр.

ЭФИР

10.00 "Супер чэннел".
17.05 Мультфильмнар.
17.35 Видеоклиплар.
19.10 "Эфир" анонслары.
19.25 Хокук каналы.
19.45 Шәһәр.
20.05 Дөнья яңалыклары.
20.15 Видеоклиплар.
20.30 Бизнес-фарватер.
20.40 "Медея". Нәфис фильм.
22.35 600 секунд.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Мультфильм.
9.30 Марафон-15 - старт.
10.15 Брейн-ринг.
11.05 Очрашулар сезнең өчен.
12.20 Кайсы йолдызларга очабыз?..
15.25 Телемикст.
16.10 Блокнот.
16.15 Мультфильмнар.
16.40 440 герц.
17.20 Йолдыз сәгате.
18.00 Яңалыклар.
18.20 Технодром.
18.35 Космонавтика көненә багышланган концерт.
20.10 Атна кайтавазы.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 "Ак киемнәр". 5 серия.
23.00 Монтаж.
23.10 Карагыз әле, кем килгән.
23.25 АТВ-брокер.
23.35 Мәгәр.
23.50 Монтаж.
0.00 Яңалыклар.
0.20 Бомонд.

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 Иртәнге концерт.
9.10 Утә яшерен.
10.30 Сабый теле белән.
11.00 Талант... һәм аңа баш иючеләр.
12.00 Буш вакыт.
12.15 "Сезне гражданка Никонорова көтә". Нәфис фильм.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Яңалыклар.
14.25 "Табыш зарарсызландырырга". Нәфис фильм.
15.50 "Кече Европа"дан репортажлар.
16.25 Там-там яңалыклары.
16.40 Американың кыргый табигате.
17.10 Чагылыш.
17.55 Тотыклар.
18.25 Коткару-911.
19.20 Россиядә бизнес.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Мәхәббәт яки акча". Нәфис фильм.
21.20 "Евгений Онегин".
21.50 Мультфильм.
22.00 Бизәмичә.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Әйдәгез, ачыклык кертик.
23.45 РФ ЮС сессиясендә.
0.00 "Яңадан синең тавышыңны ишетәм".

СИШӘМБЕ

13 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.05 Экран - балаларга.
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.30 "Биформ" фирмасы - язгы чәчүгә.
19.45 Әлли-бәлли-бәү
20.00 "Хөрмәтле редакция".
20.55 "Синьорита". 3,4 серияләр.

ЭФИР

10.00 "Супер чэннел".
17.05 Мультфильмнар.
17.45 "Эфир" анонслары.
18.00 "Индеяле-2". Нәфис фильм.
19.45 Актуаль интервью.
20.00 Дөнья турист күзлегеннән.
20.25 Телетекст.
20.40 "Эшлекле ныклык". Нәфис фильм.
22.00 600 секунд.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Шаян ноталар.
9.30 "Мария".
10.20 Провинция салоны.
10.40 Гол.
11.10 440 герц.
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Покров капкалары". Нәфис фильм.
14.35 Мультфильм.
14.50 "Ир һәм хатын". Телефильм.
15.25 Эшлекле яңалыклар хәбәрчесе.
15.40 Адам Смитның акча дөньясы.
16.10 Блокнот.
16.15 "50x50" тамашасы.
17.30 Гол.
18.00 Яңалыклар.
18.25 "Останкино" тәкъдим итә.
18.55 Шәхси милекчелек әлифбасы.
19.10 "Мария".
19.55 Тема.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 "Ак киемнәр". 6 серия.
23.05 "Останкино-93" хит-парады.
0.00 Яңалыклар.

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 Мультфильм.
9.05 Бизәмичә.
10.00 "К-2" күрсәтә...
10.55 Параллельләр.
11.10 Игелек кыл.
11.55 "Чукотка начальнигы". Нәфис фильм.
13.25 Мульти-пульти.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
14.25 Адымнар.
15.10 "Вероника".
15.30 "Бурда моден".
16.00 Телебиржа.
16.30 Там-там яңалыклары.
16.45 "Рост" студиясе.
17.15 Замоскворечьедагы бәйрәм.
18.00 Ата-аналар өчен әкиятләр.
18.30 "Электричествога мәхәббәт".
18.45 Парламент хәбәрчесе.
19.00 "Алар ничек озак көтә".
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Санта Барбара".
21.15 Халык музыка короллары оркестры юбилее.
22.00 Телефильм.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Криминаль хәбәрләр.
0.00 РФ ЮС сессиясендә.

ЧӘРШӘМБЕ

14 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.05 "Музыка дөньясына сәяхәт".
18.35 Эшлекле яңалыклар.
19.00 Татарстан.
19.30 Реклама курьеры.
19.35 "ТелеОКО".
20.20 Әлли-бәлли-бәү
20.35 Әдәби театр. А.Вергазов. "Йөрәк җыр сорый".
21.00 "Синьорита". 5, 6 серияләр.

ЭФИР

9.50 Телетекст.
10.00 "Супер чэннел".
17.05 "Әкият арты әкият".
17.45 "Эфир" анонслары.
18.00 "Кысла кеше". Нәфис фильм.
19.20 Видеоклиплар.
19.35 Дөнья бүген.
19.45 Шәһәр.
20.05 Дөнья яңалыклары.
20.15 "Унисон".
21.10 Бизнес-фарватер.
21.20 "Яңадан терелгән". Нәфис фильм.
23.00 600 секунд.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Мультфильм.
9.35 "Мария".
10.20 "Тәрәзәләре телсүзәккә караучы йорт".
10.40 "Җырла миңа, җырла, Прокошина".
11.10 "Веди".
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Өч ел". Телефильм.
14.40 Мультфильм.
15.25 Телемикст.
16.10 Блокнот.
16.15 Мультфильм.
16.45 Кызлар белән, үзара гына...
17.05 Уңышка ничек ирешергә.
17.20 Мультфильм.
17.50 Технодром.
18.00 Яңалыклар.
18.25 "Останкино" тәкъдим итә.
19.00 "Мария".
19.45 Миниатюра.
20.00 Док.фильм.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 "Ак киемнәр". 7 серия.
23.10 "Рейдта йолдызлар".
1.00 "100 С".

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 Иртәнге концерт.
9.10 Телефильм.
10.05 Ксюша янында.
10.35 Буш вакыт.
10.50 Сәнгать мәйданы.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
14.25 "03" программасы.
14.55 Утә яшерен.
15.55 Карьера әлифбасы.
16.10 Сигнал.
16.25 Там-там яңалыклары.
16.40 "Рост" студиясе.
17.10 Ерак Көнчыгыш.
17.55 Христиан программасы.
18.30 Мультфильмнар.
18.45 М.Шуфутинский.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Санта Барбара".
21.15 Зур җәнҗал.
22.00 "Нота бене" студиясе.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Зур даирә.
23.45 РФ ЮС сессиясендә.

ПӘНҖЕШӘМБЕ

15 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.00 "Гармун алдым кулыма".
18.25 Ут һәм кешеләр.
19.00 Татарстан.
19.35 Депутат каналы.
20.10Әлли-бәлли-бәү.
20.20 "Заман" телевидениесе.

ЭФИР

10.00 "Супер чэннел".
17.00 Музыкаль программа.
19.00 "Эфир" анонслары.
19.10 Кыргый табигать.
19.35 Хатын-кызлар өчен программа.
20.05 Архитектор К.Мюфке Казанда.
20.25 Телетекст.
20.40 "Машина времени" группасы.
22.00 "Игезәк кызлар". Нәфис фильм.
23.30 600 секунд.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Кара, тыңла...
9.40 "Мария".
10.25 Хайваннар дөньясында.
11.20 "Уналтыга кадәр һәм өлкәнрәкләргә".
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Балалайкин һәм К". Фильм-спектакль.
14.30 Бер йотым ирек.
15.25 Телемикст.
16.10 Блокнот.
16.20 "Останкино" тәкъдим итә.
16.45 Мультфильм.
17.15 "Сүрия буйлап".
18.00 Яңалыклар.
18.30 Миллионнар өчен мода.
19.00 "Уналтыга кадәр һәм өлкәнрәкләргә".
19.30 "Мария".
20.15 "Политика" студиясе тәкъдим итә.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 "Миллион" лоттосы.
22.10 "Доклад". Нәфис фильм.
0.00 Яңалыклар.
0.20 Бар да мөмкин.

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 Мульти-пульти.
9.15 "Нота бене" студиясе.
10.10 "Ышанам". Телеспектакль.
11.15 Мультфильмнар.
11.30 "Чернобыль алласы".
11.40 Параллельләр.
11.55 "Санта Барбара".
12.45 Борынгы Сүрия җирендә.
13.25 Видеоишегъриятъ.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
14.25 "Санников җире". Нәфис фильм.
15.55 "Туганнарым, ни турында догагыз?"
16.25 Там-там яңалыклары.
16.40 Оттырышсыз уен.
17.05 "Тәрәзә".
17.50 М-трест.
18.05 Эш кешесе.
18.35 Парламент хәбәрчесе.
18.50 Михаил Рощин.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Санта Барбара".
21.15 Мультфильм.
21.25 Хроно.
22.00 Үзгәреш.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Клип аллеясы.
23.45 РФ ЮС сессиясендә.

ҖОМГА

16 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.05 Фазыл бабай әкиятләре.
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 Видеоспорт.
19.45 Әлли-бәлли-бәү
20.00 Җомга көн кич белән.
21.00 Кардәшлеккә чикләр юк.

ЭФИР

9.50 Телетекст.
10.00 "Супер чэннел".
17.00 Мультфильмнар.
17.40 "Эфир" анонслары.
17.55 "Котылу җиңүдә". Нәфис фильм.
19.45 Шәһәр.
20.05 Дөнья яңалыклары.
20.15 Дөнья бүген.
20.25 Видеоклиплар.
20.40 "Төрмә биржасы". Нәфис фильм.
22.15 600 секунд.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Мультфильм.
9.35 "Гүзәл Василиса". Нәфис фильм.
11.00 Сәяхәтчеләр клубы.
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 Америка М.Таратута белән.
12.50 "34 нче тизйерешле". Нәфис фильм.
14.10 "01 тыңлый".
14.20 Мультфильмнар.
15.25 Бридж.
15.50 Бизнес-класс.
16.05 Блокнот.
16.10 Г.Свиридов. "Кар ява".
16.25 "Гүзәл Василиса".
17.50 Эш.
18.00 Яңалыклар.
18.20 "Останкино" тәкъдим итә.
18.45 Кеше һәм закон.
19.15 Америка М.Таратута белән.
19.45 Могҗизалар кыры.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 Атна кичесе.
21.55 "Стрип-шоу". Нәфис фильм.
23.20 Политбюро.
0.00 Яңалыклар.

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 Мультфильм.
9.10 Үзгәреш.
10.05 "Алтын типкә".
10.35 Фольклор.
11.05 Театраль сәфәр.
11.50 Буш вакыт.
12.05 "Санта Барбара".
14.00 Хәбәрләр.
14.25 Док.фильм.
14.55 Сагышлы утырмалар.
15.25 Калугада 20 нче сезон.
15.55 Телебиржа.
16.25 Там-там яңалыклары.
16.40 "Рост" студиясе.
17.10 "Сүнгән йолдыз?"
17.40 Әйдәгез, ачыклык кертик.
18.00 "Җир планетасына сөрелгән". 6 серия.
18.50 Мультфильм.
19.00 "Дөнья - маятник, яки Д.Панинның кире кайтуы".
19.30 Мульти-пульти.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Улу куркыныч түгел". Нәфис фильм.
22.00 Абзац.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Фильм-премьера.
23.45 РФ ЮС сессиясендә.
0.45 "А" программасы.

ШИМБӘ

17 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
17.00 Кино кичәсе.
19.00 Татарстан.
19.30 Әдәби театр.
19.50 Әлли-бәлли-бәү
20.05 Атналык телевизион күзәтү.
20.35 Г.Тукай бүләгенә кандидатлар. Р.Вәлиев.

ЭФИР

9.50 Телетекст.
10.00 "Супер чэннел".
15.30 Мультфильмнар.
17.10 "Күкрәү көннәре". Нәфис фильм.
18.55 Утны буйсындыручылар.
19.15 Видеоклиплар.
20.30 "Үлем биюе". Нәфис фильм.

ОСТАНКИНО

7.15 Яңалыклар.
7.35 Иртәнге гимнастика.
7.45 Пресс-экспресс.
7.55 Эшлекле кешенең шимбә иртәсе.
8.40 Моторлар дөньясында.
9.10 Марафон-15 нәниләргә.
9.35 Үзеңә үзең ярдәм ит.
10.05 Шимбә автографы.
10.35 Кеше институты.
11.05 Музыкаль киоск.
11.35 Кызыл галәм.
12.05 "Миңа үз тиңеңә карагандай кара".
13.15 "Өчлек, җиләк, туз".
13.30 "Эшләре әкияттәгедәй пешә торган ирләр". Нәфис фильм.
15.00 Яңалыклар.
15.25 Үзәк-экспресс.
15.55 Спорт программасы.
16.50 "Бүре һәм куян: 25 ел бергә".
18.10 Кызыл квадрат.
18.50 "Шәп җиләк".
19.45 "Ун цент өчен үлем". Нәфис фильм.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 "Анна Каренина". 2 серия.
22.40 Телефильм.
23.15 Яңалыклар.
23.30 Христос пасхасы.

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Дөньяга үз карашың.
8.55 Мульти-пульти.
9.05 "Ачкыч" программасы.
9.35 "Рост" студиясе.
10.05 Пигмалион.
10.35 Уен дамасы.
11.05 Сигнал экземплярлы.
11.15 Мәскәүгә кадәр ерак.
12.00 "Коллегалар". Нәфис фильм.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
14.20 Пилигрим.
15.05 Юристлар телеконкурсы.
16.05 Док.фильм.
16.50 Америка йолдызлары.
17.20 Чикләрне белмәүче футбол.
18.15 Парламент хәбәрчесе.
18.30 Сабый теле белән.
19.00 Футбол буенча Россия чемпионаты.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Тормыш, күз яшьләре һәм мәхәббәт". Нәфис фильм.
22.00 Контрастлар.
22.40 Репортер.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Якты якшәмбе алдыннан.

ЯКШӘМБЕ

18 апрель

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.00 "Тукай". Телеспектакль.
19.10 Тукай бүләгенә кандидатлар. Р.Мөхәммәдиев.
20.10 Әлли-бәлли-бәү
20.15 "Азнакаем, моңлы туган ягым".

ЭФИР

10.00 "Супер чэннел".
16.40 Мультфильмнар.
17.00 "Раштуада мин теләгән бөтен нәрсә".
18.30 Видеоклиплар.
20.20 "Бәхетсезлектән туганлашканнар". Нәфис фильм.

ОСТАНКИНО

7.20 Яңалыклар.
7.35 Иртәнге гимнастика.
7.45 "Спортлото".
8.00 Көчле рух сәгате.
9.00 Үзәк.
9.30 Иртән иртүк.
10.00 Бар да өйдә чакта.
10.35 Акыллылар һәм акыллыбашлар.
11.15 Ни билгесе астында.
12.05 "Кара Чибәр маҗаралары".
12.30 Гимнастика.
13.10 Яшь буын сайлый.
14.00 "Пиф һәм Геркулес".
14.10 Кусто командасының су асты одиссеясы.
15.00 Яңалыклар.
15.20 Туры эфирда әңгәмә.
16.00 Сәяхәтчеләр клубы.
16.50 Мультфильмнар.
17.50 Панорама.
18.30 Телелоция.
18.45 Яңалыклар.
19.00 Һөнәрләрнең тере агачы.
19.05 Промснад-концерт.
20.10 "Юпитерның ботын урлаганнар". Нәфис фильм.
22.00 Нәтиҗәләр.
22.45 Спорт уикэнды.
23.00 Матадор.
0.00 Яңалыклар.

РОССИЯ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Балалар өчен пасха бәйрәме.
9.10 "Рост" студиясе.
9.40 Сагышлы утырмалар.
10.10 "45" публицистик программасы.
10.55 "Аты-баты..."
11.25 "Көньяк Африка"дан репортажлар.
11.55 "Утыз өч". Комедия.
13.10 Винил джунглилар.
13.40 Алты сутый.
14.00 Хәбәрләр.
14.20 Юньш ташлап булмый...
14.35 NBAның иң шәп уеннары.
15.35 "Терем-квартет" ансамбле.
16.20 Познер һәм Донахью.
17.50 Диснейның тылсымлы дөньясы.
18.40 Халык фрагы.
19.40 "Экспоүзәк" тәкъдим итә.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 "Зәһәр тойгылар". Нәфис фильм.
22.10 Телеафиша.
22.25 Ксюша янында.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.30 Йолдыз яңгыры.



Зөлфәт ХӘКИМ

Аппетит

Мәхәббәтсез яшәп була. Вә ләкин ашамыйча торып булмый. Әгәр кибеттә прилавка артындагы сатучы хатынга ир-ат кызыгып карый икән, монда мәхәббәтнең бер катнашы да юк. Хәзер сатучы хатыннар ирләрне хатын-кыз буларак түгел, ә ит буларак кызыксындыралар.

Күпме еллар гел мәхәббәт турында гына язып, җырлап яттык та, әллә нишләп киттек...

Әллә эчүне ташлаганга аппетит ачылды микән безнең?.. Эчмәгәндә ашыйсы килә бит ул...

Эшләр алга таба да болай барса - хәлләр хөрти. Ачның ачуы яман. Мәхәббәт аркасында үзенә кул салган кешеләр бик күп. Ә ач кеше беркайчан да асылынмый. Ул кемне булса да тотып ашарга тырыша...

Ашыйсы килүне басар өчен бер әйбәт чара бар - йоклау. Йоклаганда ашыйсы килми.Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк йокларга кирәк. Саный китсәң, аппетитны бетерә торган чаралар күп инде ул. Ашханәдә ризыкның бәясен укыгач, аппетит шунда ук юкка чыга. Ә инде аш өләшүче хатынның төксе чыраен күргәч, бөтенләй күңел болгана башлый һәм ашыйсы килүне онытып, саф һавага чыгасың да... тәмәке төпчеге табып кабасың, шуңа куанып урам буйлап китеп барасың.

Тагын бер ун ел шундый тормыш белән яшәсәк, алла боерса, барып чыгабыз. Имезүче хайваннар кебек печән ашый башларбыз. Табигатьтә укый-яза белүче, гел күшәп, төкереп, кашынып торучы, ерткыч күзле, галстуклы һәм моңарчы әле фәнгә билгесез җанвар хасил булыр...

Телебезне дә онытсак, мөгри башларбыз.

Мәскәү тирәсеннән көтүче яллап, безне болыннарга куарлар. Шулай итеп, бәлки, рәхәткә чыгарбыз...

Тик шуны онытмагыз, ишәк сыман эшләү һәм яшәү генә кешене абруйлы итми. Шул эшләгәне өчен акчасын каера белгән, үзенең тамагын, балаларының тамагын яхшы туйдыра белгән кешене генә хөрмәт итәчәкләр - бу мәңге шулай булды.

Гафу итегез, җитди темага кереп киткәнмен... Сүз бит фәкать ашау турында гына барырга тиеш иде...

Ашыйсы килүне онытыра торган экстрасенслар бар икән... Ашыйсы килгәч, ашау турында уйламаска куша ди... Карының ачканны онытыр өчен күзне йомып ятарга кирәк икән... Шул позада тигез сулап, егерме беренче елгы ачлыкны күз алдына китерергә кирәк ди... Шуннан соң күзләреңне ачып торгач, әле исән икәнлегеңә сөенеп, тагын бераз яшисе килеп китә икән...

Аппетит югалсын өчен пычрак нәрсәләр турында күбрәк уйларга кирәк. Пычрак уйлары күп булган кешенең аппетиты начар була...

Ә сез мәхәббәт дигән буласыз... ашыйсы килгәндә үбешергә дә куркыныч... Иреннәреңне чәйни башласа... аллам сакласын.

Ач кешедә гыйшык кайгысы юк инде ул. Ә инде тамак туеп китсә, без "майга чыдый алмый" башлыйбыз. Нидер җитми башлый, юктан сәбәп табып, матавык чыгарабыз... Кеше ач булса да, тук булса да яман. Ачлы-туклы булса әйбәт...

Әле бүген аңлап булмый - эч эзләнә, ләкин билгеле түгел: ашыйсы килүдән эч пошамы, әллә мәхәббәт җитеп бетмиме?.



Журналистларның Х.Ямашев исемендәге бүләге лауреаты, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, атказанган мәдәният хезмәткәре Марат Әмирхановка 22 апрельдә 60 яшь тула. Бик күп язучыларыбыз һәм журналистларыбыз кебек ул да "Татарстан яшьләре" фатихасын алган, газета битләрендә үзенең публицистик мәкаләләрен һәм юмористик хикәяләрен бастырган кеше. Юбилее мөнәсәбәте илә Марат абыйны чын күңелдән котлыйбыз һәм укучыларыбыз игътибарына аның тагын бер шаян хикәясен тәкъдим итәбез.

Марат ӘМИРХАНОВ

КЫТЫК

Автобус корсаклы хатын кебек бүртенгән. Кымшанырлык та түгел. Адәм исеннән башлар әйләнә. Шофер йөрешне акрынайткан яки тизләткән араларда гына зур сагыз кисәгенә әверелгән халык өере җә алга, җә артка сөрлегеп-сөрлегеп куя.

Чираттагы сөрлегүдә Әбелмәлихнең кулы ниндидер кайнар һәм йонлы нәрсәгә төртелде.

Автобуска утыруга, буйга үзе чамасындарак бер яшь ханым янына китереп кысканнар иде Әбелмәлихне. Ул берничә минут эчендә әлеге затның тән төзелешен бөтен ваклыкларына кадәр үзләштереп өлгерде. Итчәннәрдән димәс иде, әмма коры сөяк тә түгел, кайберәүләрнеке шикелле кабыргалары төртеп тормый. Бәлтырлары тыгыз, ихтимал, спорт белән шөгыльләнәдер, җә студент-мазардыр. Йомшак җире гүпчем акылны алырлык. Әбелмәлих инде баядан бирле онытылып китеп бер-бер дуамаллык кылудан коты очып бара, тик урынын үзгәртергә берничек тә җай чыкмый. Җә, хода, сабырлык бир дип, Әбелмәлих әбисе өйрәткән бердәнбер доганы күңеленнән кабатлый башлады: әлиф, би, ти, си, җим, ха, дәл, зәл...

- Уф, тыным кысыла, - дип уйламаганданитмәгәндә ханым телгә килде.

- Минем дә башка чарам юк, - диде Әбелмәлих, аклангандай.

- Мин сезнең белән килешәм, - дип, ханым әңгәмә учагына күра сипте.

Бәрәч, дип уйлады Әбелмәлих, борчак пешәр төсле ич моның белән, үзе авызга керәм дип тора лабаса, йотасы гына.

- Сез... ни... килешәсез, димәк ки, - диде ул калтыранган тавыш белән.

- Әйе.

Ханымның җавабы Әбелмәлихкә тәвәккәллек тә өстәде.

- Әйдә соң, алайса, бүген кич күрешик...

Кинәт кенә ханым гәүдәсен турайтты да, еландай бөтергәләнеп, Әбелмәлихка угын чәчте:

- Нахал!

Әбелмәлих күршесенең бу сүзләрен чытлыклану дип кенә кабул итте. Шуңа күрә аның колагына:

- Мин бит сизеп киләм, - дип пышылдады.

- Бу мөмкин түгел!

- Соң, алайса нишләп...

Шул мизгелдә әңгәмә өзелде, чөнки соңгы тукталышка җиткән автобус "дырк!" итеп куйды да халык дулкыны аларны шампань бөкесе кебек тышка атып чыгарды.

Урамда Әбелмәлих чак артына аумады: җиңенә, беләкләренә дөге кисәкләре ябышып каткан иде. Баксаң-күрсәң, аның кулы әлеге ханымның сумкасына кереп киткән булган икән һәм сылукайның әбәтенә эләккән. Ханым, суынмасын диптер инде, әбәтен җон оекбаш эченә тыккан булган.

"Аңгыра сарык!" - диде Әбелмәлих тешен кысып һәм, үз-үзенә шундый объектив бәя биргәннән соң, юлын дәвам итте.

Гали ГЫЙЗЗӘТ

Дини такмаклар

Уразага керәбез,
Фарыз диеп беләбез.
Ризык табу кыенлашты -
Гадәтләнеп киләбез.

Мөселманга файда гына

Ач торырга өйрәнгән...
Озакламый аяк атлап
Чыгалмабыз өйләрдән.

Бәрәңге кайный казанда,
Сәхәр ашарбыз таңда.
Ураза тота Иван да...
Бәлки кирәк иманга?
Амин!

Син яхшы идең...

(Некролог)

Син юк инде. Аһ, кызганыч! Сине хәзер сагынып искә алырга гына калды.

Их! Исләргә төшәсең дә, күзләрдән яшьләрне агызасың. Балалык чорыннан алып үлгәнчегә кадәр сиңа искиткеч зур ихтирам белән карарга өйрәнгән, гомер буе сиңа гашыйк булган әллә ничә миллион колыңны чиксез хәсрәткә салып, урыныңа ертык характерлы алмаш калдырып, араларыбыздан мәңгелеккә югалдың.

У-у! Нинди кадерле идең син! Кечкенә генә булсаң да, шагыйрь әйтмешли, олы иде синең күңелең. Кадереңне белмәдек кенә.

Ә бит син Политбюро әгъзалары белән Кремльләргә ничек йөрсәң, без гади бәндәләр белән дә шундый ук беркатлы мөнәсәбәттә булдың : бичара сәрхүшләр белән кибетләргә кереп, аларны үлемнән коткара идең, синнән башка тегүче - җеп, язучы - каләм, тәмәке тартучы бер кап шырпы ала алмый иде. Барысына да син кирәк идең.

Их, без! Белмәдек кадереңне! Хәзер генә синең зур мөмкинлекләреңне һәм тыйнаклыгыңны шаклар катып искә алабыз. Син үлгәч кенә аңлый башладык: олы мәхәббәткә чын-чынлап лаек булгансың икән син. Ә без...

Син чын патриот булып яшәдең, бөек патриот булып тормыштан киттең. Аркаңа СССР дигән бөек дәржаваның данлы гербы сурәтләнгән иде, аңа бер тап та төшермичә яши белдең.

Хуш инде, хуш.

Мәңгегә шундый якын һәм сөекле Вак Акча! Синең исемеңне беркайчан да онытмабыз: 1, 2, 3, 5 тиенлек Бакыр, 10, 15, 20, 50 тиенлек Көмеш. Якты истәлегең күңелләрдә мәңге сакланыр.

Кәгазь Сумнарны каһәрләп һәм Сине юксынып, елый-елый соңгы юлга озатып калучы колларың исеменнән Җәүдәт ЮНЫС.

КӨЛДЕРГЕЧЛӘР

- Исәнмесез, Гали Вәлиевич! Сезне бөтенләй танырлык түгел. Әле кайчан гына сез тәбәнәк буйлы, симез һәм пеләш идегез, ә хәзер - озын буйлы, арык һәм бөдрә чәчле. Бик нык үзгәргәнсез.

- Мин Гали Вәлиевич түгел.

- Кара, исемен дә үзгәрткән.

* * *

Горбачев аракы кибете янынннан узып бара. Озын чират янына туктап сорау бирә.

- Арагызда коммунистлар бармы?

- Бар! - дип кычкыра чират.

- Куарга кирәк!

- Бик куар идек тә, шикәре юк бит аның, Михаил Сергеевич!

* * *

- Хатыныма санаторийга путевка алган идем. Бик кыйммәткә төште, әмма үзен аклады.

- Тазарып кайттымы?

- Юк, бөтенләй кайтмады.

* * *

Ике ахирәт очраша.

- Тормышларың ничек дип сорар идең ичмасам, Сания.

- Тормышларың ничек?

- Әй, сорап та торма!

* * *

Ике ир сөйләшә.

- Минекенең аягы кыр кәҗәсенеке кебек.

- Нәфис һәм озын инде алайса.

- Юк. Нечкә һәм йонлы.

* * *

Бер ир эшләгән җиренә шалтырата:

- Гали Вәлиевич, мин бүген килә алмам инде.

- Нәрсә булды?

- Хатын биш мең сумлык акчасын югалткан.

- Ә синең монда ни катнашың бар?

- Мин ул акча өстендә басып торам.

* * *

Күз төбеңә кем "фонарь" куйды?

- Кичә туй сәяхәтеннән кайткан дустымны очраткан идем...

- Соң?

- Хатынын аңа мин димләгән идем.

* * *

Хатыны - иренә:

- Безнең малай скрипкада уйнарга өйрәнәчәк!

- Аның бит ишетү сәләте ташка үлчим!

- Монда ишетүнең ни катнашы бар? Аны бит тыңларга түгел, ә уйнарга өйрәтәчәкләр!

* * *

Ире өенә шалтырата:

- Бу синме, кадерлем?

- Юк, бу мин, - дип җавап бирә хатыны.

* * *

Мичурин тәгълиматын дәвам иттерүче профессор институтта лекция укый.

Секретарь кыз, аны бүлдереп, күңелсез хәбәр җиткерә:

- Профессор, сезнең хатыныгызны "Ашыгыч ярдәм" белән алып киткәннәр.

- Сукыр эчәкме?

- Юк. Ул укроп җыярга дип алма агачына менгән булган. Шул чагында башына карбыз өзелеп төшкән...



Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751
ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005

Индекс - 54121
Тираж - 200.000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6076